**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР № 4**

Димтамак авылы 2019 елның 29 марты

2012 елның 24 апрелендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртип саклау Кагыйдәләрен раслау турында"гы № 5 Карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртип саклау Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**3 бүлек. Территорияне җыештыруны оештыру тәртибе, территориядә чисталык һәм тәртип тәэмин итү**

3 бүлекнең 3.2 пунктына – Территорияне җәйге-көзге җыештыру -

1) түбәндәге эчтәлектәге 3.2.2. пунктча өстәргә :

Язгы-җәйге чорда юридик затлар (шәхси эшмәкәрләр) һәм физик затлар үз милекләрендә, биләмәләрендә һәм файдалануларында булган җир кишәрлекләрендә Сосновский балтырганын (борщевик Сосновского) юк итәргә тиеш.

2. Әлеге карарны http://jutaza.tatar.ru адресы буенча Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Димтамак авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгына йөкләргә.

Димтамак авыл җирлеге башлыгы урынбасары С.М.Хәлиуллина